ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2017 Казан ш. № 6-115/тп

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен 2017 елга стандартлаштырылган тариф ставкалары, максималь куәт бирәмлеге өчен ставкалар һәм түләү хисаплау буенча формулалар билгеләү турында» 14.12.2016 № 6-216/тп карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясеннән кулланучыларның энергия кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерүче объектларны, шулай ук челтәр хуҗаларыныкы һәм бүтән затларныкы булган электр хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләре, Федераль тарифлар хезмәтенең «Электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 11 сентябрендәге 209-э/1 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен 2017 елга стандартлаштырылган тариф ставкалары, максималь куәт бирәмлеге өчен ставкалар һәм түләү хисаплау буенча формулалар билгеләү турында» 14.12.2016 № 6-216/тп карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Шушы карарның 4, 6, 8, 10, 12, 14, 16, 18, 20, 22, 24, 26, 28, 30, 32, 34, 38 кушымталарына туры китереп, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү хисаплау буенча максималь куәт берәмлегенә ставкалар билгеләргә.»;

1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 17 пунктны өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «17. | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 49 | 14 | 14 | 9» |

шушы карар кушымтасына туры китереп, 38 кушымта өстәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
13.10.2017 № 6-115/тп карарына
кушымта «Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.12.2016 № 6-216/тп карарына
38 нче кушымта

## «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү хисаплау буенча максималь куәт берәмлегенә ставкалар

сум/кВт (НДС исәпкә алмыйча)

| Шартлы билгеләр | Чараның аталышы | 1 кВ кадәр | | | 6-10 кВ | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 150 кВТ кадәр | 150 кВт башлап 670 кВт кадәр | 670 кВт башлап 8 900 кВт кадәр | 150 кВТ кадәр | 150 кВт башлап 670 кВт кадәр | 670 кВт башлап 8 900 кВт кадәр |
| $А_1$ | Челтәр оешмасы тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә техник шартлар әзерләү һәм бирү | 49 | | | | | |
| $А_2$ | Челтәр оешмасы тарафыннан «соңгы миль» төзелеше буенча проект документациясен эшләү: | | | | | | |
| $А_{2.1}$ | һава линияләре төзү | 681,71 | 751,27 | 833,54 | 758,66 | 853,40 | 888,45 |
| $А_{2.2}$ | траншеяләрдә кабель линияләре төзү | 326,43 | 384,27 | 419,81 | 511,30 | 597,50 | 722,93 |
| $А_{2.3}$ | яссы-юнәлтеп бораулау ысулы белән кабель линияләре төзү (ГНБ) | 2 180,22 | 2 237,72 | 2 393,16 | 2 651,78 | 3 190,54 | 3 234,67 |
| $А_{2.4}$ | бүлемтекләү пунктлары төзү | 163,18 | 163,18 | 163,18 | 488,21 | 488,21 | 106,23 |
| $А_{2.5}$ | 35 кВ кадәр көчәнеш дәрәҗәсендәге КТП, РТП төзү | 454,36 | 560,72 | 1 115,80 | 454,36 | 560,72 | 1 115,80 |
| $А_3$ | Челтәр оешмасы тарафыннан «соңгы миль» төзелешенә бәйле чараларны үтәү: | | | | | | |
| $А_{3.1}$ | һава линияләре төзү | 9 738,64 | 10732,33 | 11 907,63 | 10 838,10 | 12 191,41 | 12 692,14 |
| $А_{3.2}$ | траншеяләрдә кабель линияләре төзү | 4 663,32 | 5 489,57 | 5 997,23 | 7 304,30 | 8 535,64 | 10 327,54 |
| $А_{3.3}$ | яссы-юнәлтеп бораулау ысулы белән кабель линияләре төзү (ГНБ) | 31 145,89 | 31967,42 | 34 187,97 | 37 882,42 | 45 579,16 | 46 209,64 |
| $А_{3.4}$ | бүлемтекләү пунктлары төзү | 2 167,91 | 2 167,91 | 2 167,91 | 6 974,48 | 6 974,48 | 1 411,34 |
| $А_{3.5}$ | 35 кВ кадәр көчәнеш дәрәҗәсендәге КТП, РТП төзү | 6 490,85 | 8 010,31 | 15 940,14 | 6 490,85 | 8 010,31 | 15 940,14 |
| $А_4$ | Челтәр оешмасы тарафыннан мөрәҗәгать итүченең техник шартларны үтәвен тикшерү | 14 | | | | | |
| $А_5$ | Мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган Җайланмалары энергетика | 14 | | | | | |

| | | |
|---|---|---|
| | күзәтчелеге буенча федераль дәүләт органы вазыйфаи заты тарафыннан каралганда челтәр оешмасының катнашуы[1] | |
| $A_6$ | Электр челтәрләрендә җайланмаларны тоташтыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү буенча фактик гамәлләр | 9 |

Искәрмә. Максималь куәт бирәмлеге өчен ставкалар 2017 елгы бәяләрдә хисапланды.

---

[1] Әлеге ставка түбәндәгеләр өчен технологик тоташтыруны башкарганда түләү хисаплаганда кулланылмый:

– энергия кабул итү җайланмаларының максималь куәте 150 кВт югары һәм 670 кВт кимрәк булган юридик затлар яисә шәхси эшкуарлар өчен, – аларның энергия кабул итү җайланмаларын 20 кВ кадәрге көчәнеш классына караучы электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашырганда;

– икенче яисә өченче ышанычлылык категориясенә караучы, максималь куәте 150 кВт кадәр тәшкил итүче энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру максатларында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен (тоташтыруның әлеге ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып);

– вакытлыча технологик тоташтыру максатларында мөрәҗәгать итүчеләр өчен;

– максималь куәте 15 кВт кадәр булган, көнкүреш һәм башка төрле, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган ихтыяҗлар өчен файдаланыла торган һәм бер чыганак буенча электр белән тәэмин итү күздә тотылган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру максатларында физик затлар өчен (тоташтыруның әлеге ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып).

Күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясеннән кулланучыларның энергия кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерүче объектларны, шулай ук челтәр хуҗаларыныкы һәм бүтән затларныкы булган электр хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләренең 18, 18(1)-18(4) пунктларындагы нигезләмәләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүченең объектларын эксплуатациягә кертү өчен энергетика күзәтчелеге буенча федераль дәүләт органыннан рөхсәт алу таләп ителми. Күрсәтелгән искәрмәләр челтәр оешмалары объектларын технологик тоташтыру очракларына кагылмый.»

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге